ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 18.06.2020** **№ 476**

**2020 елга муниципаль юл фонды акчалары исәбенә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле әһәмияткә ия булган гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре муниципаль программасын раслау турында**

2019 елның 30 декабрендәге 1271 номерлы «2020 елга Татарстан Республикасының гомуми кулланылыштагы юлларында юл эшләре турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә КАРАР БИРӘ:

1. Тәкъдим ителә торган 2020 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында җирле әһәмияткә ия булган гомуми кулланылыштагы юлларда юл эшләре муниципаль программасын муниципаль юл фонды акчалары хисабына 29 300,0 мең сум, һәм юл хәрәкәте иминлеге буенча чараларга (2020 елның 1 нче январена калганнар хисабына) 3290,65875 мең сум итеп расларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ф.Хакимуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин

Расланды
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының 2020 елның
18 июнендәге 476 нчы номерлы
карары белән

# 2020 ЕЛГА МУНИЦИПАЛЬ ЮЛ ФОНДЫ АКЧАЛАРЫ ИСӘБЕНӘ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ҖИРЛЕ ӘҺӘМИЯТКӘ ИЯ БУЛГАН ГОМУМИ ФАЙДАЛАНУДАГЫ ЮЛЛАРЫНДА ЮЛ ЭШЛӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ

## ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2020 елга муниципаль юл фонды акчалары исәбенә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле әһәмияткә ия булган гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре муниципаль программасы |
| Программаны эшләп чыгару өчен җирлек (норматив актның исеме, номеры һәм датасы) | 1. Россия Федерациясе Бюджет кодексы.<br>2. Татарстан Республикасы Бюджет кодексы.<br>3. “2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында” Татарстан Республикасы Законы.<br>4. 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Биектау муниципаль районы бюджеты.<br>5. Биектау муниципаль районы башкарма комитетының муниципаль юл фондын булдыру һәм муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану тәртибен раслау турында карар.<br>6. 2020 елга Татарстан Республикасында юл эшләре программасы.<br>7. 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль закон.<br>8. 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” Федераль закон.<br>9. Биектау муниципаль районы башкарма комитетының “2020 елга Биектау муниципаль районында юл эшләре” муниципаль программасын эшләп чыгару турында” карары. |
| Программаның координаторлары | 1. Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы.<br>2. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалагы министрлыгы.<br>3. Татарстан Республикасы юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе. |
| Программаның заказчысы | “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты” МКУ муниципаль берәмлеге. |
| Программаны төп эшләп чыгаручылар | Биектау муниципаль районы башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге. |

| | |
|---|---|
| Программаның максатлары һәм бурычлары | - транспорт чыгымнарын киметүне тәэмин итүче заманча, нәтиҗәле транспорт инфраструктурасы үсеше;<br>- социаль тотрыклылыкны саклау, сорауны канәгатьләндерү һәм автомобиль йөртүләрен мөмкин итү юлы белән икътисадны үстерү, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү мәсьәләләрен дә кертеп шартлар тудыру;<br>- җирле әһәмияткә ия булган гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген тәэмин итү, капиталь ремонт һәм күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренә ремонт, Биектау муниципаль районы торак пунктларының күпфатирлы йортлары ишегалды территорияләренә керү;<br>- Биектау муниципаль районы торак пунктларының юл-урам челтәрләрен юллар төзү һәм ремонтлау юлы белән норматив халәткә китерү;<br>- халыкка ел әйләнесендә йөри ала торган бердәм юл челтәрен формалаштыру өчен, автоюлларның үткәрә алу мөмкинлеген арттыру, төп транспорт агымын торак пункт читләренә чыгару һәм авыл торак пунктларын гомуми кулланылыштагы юл челтәрләре белән кушу юлы белән шартлар тудыру;<br>- төбәк һәм муниципальара әһәмияткә ия булган гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларының тотрыклы эшләвен тәэмин итү, төбәк һәм муниципальара әһәмияткә ия булган гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары буенча хәрәкәт итүнең ышанычлылыгын һәм иминлелеген тәэмин итү. |
| Программаның максатчан индикаторлары | - норматив таләпләргә җавап биргән автомобиль юллары озынлыгы артуы;<br>- каты өслекле юллар буенча гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары челтәре белән ел дәвамында даими элемтә белән тәэмин ителгән авыл торак пунктлары саны артуы;<br>- норматив таләпләргә җавап биргән гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары озынлыгы һәм аларда корылмалар саны артуы. |
| Программаны тормышка ашыру сроклары | 2020 елның 1 нче ноябренә кадәр |
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | 2020 елга финанслау күләме 32590658,75 сумны тәшкил итә.<br>- автомобиль һәм туры кудырыла торган бензинга, дизель ягулыгына, Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган, дизельле һәм карбюраторлы, инжектор двигательләр өчен мотор майларына акцизлар; |

| | |
|---|---|
| | - Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр буларак кертемнәр;<br>- физик һәм юридик затлардан кертемнәр, шул исәптән ирекле ярдәм. |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре | Программа чараларын тормышка ашыру мөмкинлек бирәчәк:<br>- халыкның иминлек дәрәҗәсен арттыру;<br>- районның инвестицион җәлеп итүчәнлеген арттыру;<br>- хуҗалык субъектларының һәм тулаем районның социальикътисади үсеше;<br>- авыл торак пунктларын каты өслекле юлларының гомуми кулланылыштагы юллар белән бәйләүче юллар челтәре озынлыгын арттыру;<br>- каты өслекле юллар буенча гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары челтәре белән ел әйләнәсендә элемтә белән тәэмин ителгән авыл торак пунктлары саны артуы;<br>- юлларның канәгатьләнерлек булмаган сыйфаты, хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләре һәм аларда зыян күрүчеләр санын киметү аркасында транспорт чараларының тузуын киметү. |

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Муниципаль юл фонды Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179.4 статьясы 5 пункты нигезендә формалаша һәм кулланыла.

1.2. Муниципаль юл фонды – җирле (муниципаль) әһәмияткә ия булган гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген тәэмин итү, капиталь ремонт һәм күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренә ремонт, торак пунктларының күпфатирлы йортлары ишегалды территорияләренә керү юлларына карата юл эшчәнлеген финанс тәэмин итү максатында кулланылырга тиешле муниципаль берәмлек бюджеты чараларының бер өлеше.

1.3. Юл фонды чаралары максатчан билгеләнешле һәм юл эшчәнлеген тәэмин итү белән бәйле булмаган ихтыяҗларны канәгатьләндерү белән бәяле булмаган ихтыяҗларга алынырга яки тотылырга тиеш түгел.

## 2. ЮЛ ФОНДЫН БАРЛЫККА КИТЕРҮ ЧЫГАНАКЛАРЫ

2.1. Юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләме Биектау муниципаль районының җирле бюджет турында карары белән чираттагы финанс елына һәм планлы чорга түбәндәгеләрдән җирле бюджет кеременең фаразланган күләме суммасыннан ким булмаган күләмдә раслана:

2.1.1. Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган автомобиль бензинына һәм турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, дизель һәм карбюратор (инжектор) двигательләр өчен мотор майларына чираттагы финанс елына

һәм план чорына Татарстан Республикасы законы белән расланган дифференциацияләнгән нормативлар нигезендә Биектау муниципаль районы бюджетына күчерелә торган акцизлар;

2.1.2. Җирле (муниципаль) әһәмияткә ия булган гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген тәэмин итү, капиталь ремонт һәм күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләренә ремонт, торак пунктларының күпфатирлы йортлары ишегалды территорияләренә керү юлларына карата юл эшчәнлеген тормышка ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр сыйфатында кертемнәр.

2.1.3. Юл эшчәнлеген финанс тәэмин итү өчен  физик һәм юридик затлардан ирекле кертемнәр, шул исәптән җирле (муниципаль) әһәмияткә ия булган гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген тәэмин итү.

2.2. Муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләренә чираттагы финанс елына хисап финанс елында фактта кергән һәм җирле бюджет керемнәренең әлеге пунктында күрсәтелгән аны формалаштырган вакыттагы фаразланган күләмендәге аерымлыкларны исәпкә алып, төзәтмәләр кертелергә тиеш.

2.3. Агымдагы финанс елында кулланылмаган юл фонды бюджет ассигнованиеләре чираттагы финанс елына юл фонды бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлдереләләр.

## 3. ЮЛ ФОНДЫ ЧАРАЛАРЫ ЧЫГЫМНАРЫ ЮНӘЛЕШЛӘРЕ

3.1. Муниципаль юл фонды чаралары юнәлдереләләр:

3.1.1. җирле (муниципаль) әһәмияткә ия булган гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын проектлау, төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту;

3.1.2. күпфатирлы йортларның ишагалды территорияләрен, торак пунктларның күпфатирлы йортлары ишегалды территорияләренә керүне капиталь ремонтлау һәм ремонтлау;

3.1.3. һәрбер объект буенча бүленүнең 2020 елга расланган юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләме  әлеге Программага 1 нче кушымтада сурәтләнгән.

## 4.  ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

4.1. Программада түбәндәге максатлар билгеләнгән:

4.1.1. Транспорт чыгымнарын киметүне тәэмин итүче заманча, нәтиҗәле транспорт системасы үсеше;

4.1.2. Социаль тотрыклылыкны саклау, сорауны канәгатьләндерү һәм автомобиль йөртүләрен мөмкин итү юлы белән икътисадны үстерү, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү мәсьәләләрен дә кертеп шартлар булдыру.

4.2. Күрсәтелгән максатларга ирешү түбәндәге бурычларны чишү юлы белән тәэмин ителә:

4.2.1. Халык өчен ел әйләнәсендә йөри ала торган бердәм юл челтәрен формалаштыру өчен, автоюлларның үткәрә алу мөмкинлеген артыру, авыл

торак пукнтларын гомуми кулланылыштагы юл челтәрләре белән тоташтыру юлы белән шартлар тудыру.

4.2.2. Җирле әһәмияткә ия булган гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларының тотрыклы эшләвен тәэмин итү, җирле әһәмияткә ия булган гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары буенча йөрүнең ышанычлылыгын һәм куркынычсызлыгын арттыру.

4.3. Җирле әһәмияткә ия булган гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары үсешенең төп приоритетлары булып тора:

4.3.1. Норматив таләпләргә җавап бирмәгән җирле әһәмияткә ия булган гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары өлеше киметү;

4.3.2. Пассажир, мәктәп автобус хәрәкәте маршрутларының транспорт-эксплуатация халәтен камилләштерү;

4.3.3. Автоюллар буенча хәрәкәт куркынычсызлыгы дәрәҗәсен арттыру, шул исәптән автомобиль юлларын җиһазландыру юлы белән.

## 5. ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУНЫҢ ТӨП ЮНӘЛЕШЛӘРЕ

Программа тарафыннан Программаның максатларына ирешү һәм бурычларын хәл итүгә юнәлдерелгән  төп ике чараны тормышка ашыру  күздә тотыла.

Бурычларны хәл итү һәм чараларны тормышка ашыру эзлеклелеге Биектау районы админстрациясе тарафыннан билгеләнелә.

1нче бурыч – халык өчен ел әйләнәсендә йөри ала торган бердәм юл чәлтәрен формалаштыру өчен, автоюлларның үткәрә алу мөмкинлеген артыру, авыл торак пукнтларын гомуми кулланылыштагы юл челтәрләре белән тоташтыру юлы белән шартлар тудыру.

Әлеге чараларны башкару өлкә бюджетыннан финанслау алган очракта мөмкин.

2нче бурыч – җирле әһәмияткә ия булган гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларының тотрыклы эшләвен  тәэмин итү, җирле әһәмияткә ия булган гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларының ышанычлылыгын һәм куркынычсызлыгын арттыру - җирле әһәмияткә ия булган гомуми кулланылыштагы автмобиль юлларын ремонтлау һәм карап тоту буенча  чаралар комплексын тормышка ашыру юлы белән хәл ителә.

Программа чараларын тормышка ашыру булган финанслау күләмнәре нигезендә тормышка ашырыла:

норматив документларның таләпләрен һәм хәрәкәт куркынычсызлыгы шартларын истә тотып, автомобиль юлларын һәм аларда ясалма корылмаларны ел әйләнәсендә карап тоту;

җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын һәм алардагы ясалма корылмаларны комиссия каравы уздыру һәм транспорт-эксплуатация халәтенә бәя бирү, паспортлаштыру уздыру;

проект-тикшеренү эшләрен башкару һәм смета документациясен эшләү.

Әлеге чара буенча эшчәнлек җирле әһәмияткә ия булган гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары буенча транспорт чаралары хәрәкәте өчен юл куркынычсызлыгы шартларын арттыруга юнәлдерелгән.

## 6. ЮЛ ФОНДЫ БЮДЖЕТ АССИГНОВАНИЕЛӘРЕН ФОРМАЛАШТЫРУ ҺӘМ ТОТУ БУЕНЧА КОНТРОЛЬ ҺӘМ БАШКАРУ ТУРЫНДА ХИСАП

Юл фонды чараларын тоту буенча контрольне Биектау муниципаль районы башкарма комитеты тормышка ашыра.

1 нче кушымта
2020 елга муниципаль юл фонды акчалары исәбенә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле әһәмияткә ия булган гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре муниципаль программасына
18.06.2020 № 476

**2020 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында җирле әһәмияткә ия булган гомуми кулланылыштагы юлларда юл эшләре муниципаль программасына кертелгән җирле әһәмияткә ия объектлар исемлеге**

| № т/б | Объектның исеме | Егәрлек, км | Гамәлдәге бәяләрдә капиталь салымнар, мең сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Ремонт Молодежная ур. (Биектау ав.) | 0,221 | 29 300,00 |
| 2. | Биектау авылы балалар бакчасына килү юлын ремонтлау | 0,487 | |
| 3. | Ремонт Светлая ур. Биектау ав. | 0,500 | |
| 4. | Ремонт Чернышевская ур. (Чернышевка ав.) | 0,571 | |
| 5. | Ремонт Авдеев ур. ( Дөбьяз ав.) | 0,288 | |
| 6. | Ремонт Центральная ур. (Урта Алат ав.) | 0,575 | |
| **2020 елга МЮФ планы буенча барлыгы** | | | 29 300,00 |
| **2014-2020 елларда кергән муниципаль юл фонды чараларының калган өлеше хисабына чаралар** | | | |
| Юл хәрәкәте иминлеге буенча чаралар, шул исәптән: | | | |
| Техник чаралар җайланмасы (җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу юлы билгеләре белән берләштерелгән ясалма тигезсезлек урнаштыру, билгеләр урнаштыру 1.17, 5.20, 3.24, 5.19.1, 5.19.2) "Биектау УГБМ №2" МББМУ, Биектау ав., Полковая ур. | | 1 комп. | 118,95 |
| Техник чаралар җайланмасы (җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу юлы билгеләре белән берләштерелгән ясалма тигезсезлек урнаштыру, билгеләр урнаштыру 1.17, 5.20, 3.24, 5.19.1, 5.19.2) Биектау т/юл ст. бист., Советская ур. (юл аркылы чыгу янында) | | 1 комп. | 139,49 |

| | | |
|---|---|---|
| Техник чаралар җайланмасы (җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу юлы билгеләре белән берләштерелгән ясалма тигезсезлек урнаштыру, билгеләр урнаштыру 1.17, 5.20, 3.24, 5.19.1, 5.19.2) Биектау т/юл ст. бист., Советская ур. | 1 комп. | 121,77 |
| Эчке поселок автомобиль юлларында җәяүле кичүләрдә термопластик горизонталь киңлек урнаштыру Биектау т/юл ст. бист. | 200 кв.м | 850,47 |
| Техник чаралар җайланмасы (җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу юлы билгеләре белән берләштерелгән ясалма тигезсезлек урнаштыру, билгеләр урнаштыру 1.17, 5.20, 3.24, 5.19.1, 5.19.2) "Ямаширмә УГБМ" МБГБУ Ямаширмә ав., Школьная ур, 13й | 1 комп. | 147,99 |
| Техник чаралар җайланмасы (җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу юлы билгеләре белән берләштерелгән ясалма тигезсезлек урнаштыру, билгеләр урнаштыру 1.17, 5.20, 3.24) "Алан-Бәксәр ТГБМ" МБГБУ Алан-Бәксәр, Школьная ур, 13й | 1 комп. | 55,10 |
| Техник чаралар җайланмасы (җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу юлы билгеләре белән берләштерелгән ясалма тигезсезлек урнаштыру, билгеләр урнаштыру 1.17, 5.20, 3.24, 5.19.1, 5.19.2) "Мәмдәл УГБМ" МБГБУ Мәмдәлав. Кооперативная ур., 1 а й. | 1 комп. | 132,32 |
| Техник чаралар җайланмасы (җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу юлы билгеләре белән берләштерелгән ясалма тигезсезлек урнаштыру, билгеләр урнаштыру 1.17, 5.20, 3.24, 5.19.1, 5.19.2) "Олы Кавал ТГБМ" МБГБУ, Олы Кавал ав., Школьная ур. 13й. | 1 комп. | 132,32 |
| Техник чаралар җайланмасы (җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу юлы билгеләре белән берләштерелгән ясалма тигезсезлек урнаштыру, билгеләр урнаштыру 1.17, 5.20, 3.24, 5.19.1, 5.19.2) Биектау ав., Центральная һәм Полковая урамнары кисешүе | 1 комп. | 120,87 |
| Техник чаралар җайланмасы (җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу юлы билгеләре белән берләштерелгән ясалма тигезсезлек урнаштыру, билгеләр урнаштыру 1.17, 5.20, 3.24, 5.19.1, 5.19.2) "Биектау УГБМ №1" МБГБУ, Биектау ст., Гагарин ур., 9й. | 1 комп. | 106,42 |
| Юл билгеләре урнаштыру (1.23, 2.4, 2.1, 2.3.5, 8.13, 3.4, индивидуаль билге). Биектау муниципаль районы эчке посёлок автом. юллары | 74 знака | 612,12 |

| | | |
|---|---|---|
| Техник чаралар җайланмасы (җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу юлы билгеләре белән берләштерелгән ясалма тигезсезлек урнаштыру, билгеләр урнаштыру 1.17, 5.20, 3.24)Биектау ав., Дачная ур., 30 й. янында | 1 комп. | 57,68 |
| Техник чаралар җайланмасы (җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу юлы билгеләре белән берләштерелгән ясалма тигезсезлек урнаштыру, билгеләр урнаштыру 1.17, 5.20, 3.24)Биектау ав., 2 нче Молодежная ур. Отрадная ур. кисешүендә | 1 комп. | 52,13 |
| Техник чаралар җайланмасы (җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу юлы билгеләре белән берләштерелгән ясалма тигезсезлек урнаштыру, билгеләр урнаштыру 1.17, 5.20, 3.24, 5.19.1, 5.19.2) "Чернышевка ТГБМ", Чернышевка ав. | 1 комп. | 98,30 |
| Техник чаралар җайланмасы (җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу юлы билгеләре белән берләштерелгән ясалма тигезсезлек урнаштыру, билгеләр урнаштыру 1.17, 5.20, 3.24)Биектау ав., Бикинеев ур. (340 урынга төзелүче бал./бакчасы янында) | 1 комп. | 66,63 |
| Техник чаралар җайланмасы (җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу юлы билгеләре белән берләштерелгән ясалма тигезсезлек урнаштыру, билгеләр урнаштыру 1.17, 5.20, 3.24)Биектау ав., Дальняя ур. (мәчет янында) | 1 комп. | 51,51 |
| Техник чаралар җайланмасы (җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу юлы билгеләре белән берләштерелгән ясалма тигезсезлек урнаштыру, билгеләр урнаштыру 1.17, 5.20, 3.24, 5.19.1, 5.19.2) "Красносельский "Ак Каен" бал./бакчасы", Березовка бист., Центральная ур., 7й. | 1 комп. | 95,88 |
| Техник чаралар җайланмасы (җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу юлы билгеләре белән берләштерелгән ясалма тигезсезлек урнаштыру, билгеләр урнаштыру 1.17, 5.20, 3.24, 5.19.1, 5.19.2) Юртыш ав., Кооперативная ур. | 1 комп. | 133,04 |
| Техник чаралар җайланмасы (җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу юлы билгеләре белән берләштерелгән ясалма тигезсезлек урнаштыру, билгеләр урнаштыру 1.17, 5.20, 3.24) Биектау ав., Мичурин ур. | 1 комп. | 60,60 |
| Техник чаралар җайланмасы (җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу юлы билгеләре белән берләштерелгән ясалма тигезсезлек урнаштыру, билгеләр урнаштыру 1.17, 5.20, 3.24) Биектау ав., Полковая ур. | 1 комп. | 76,46 |

| | | |
|---|---|---|
| Техник чаралар җайланмасы (җәяүлеләр өчен юл аркылы чыгу юлы билгеләре белән берләштерелгән ясалма тигезсезлек урнаштыру, билгеләр урнаштыру 1.17, 5.20, 3.24) Биектау ав., Совхозная ур. | 1 комп. | 60,60 |
| Бүленмәгән чаралар | | 0,00875 |
| **2014-2020 елларга МЮФ чараларының фактта калганның барлыгы** | | **3 290,65875** |